**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 июнендәге 2058 номерлы карары**

**Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында»гы әмеренең 4.1 пунктына таянып, **карар бирәм**:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2026 елның 1 июленнән 16,08 процентка тигез дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**